**<u>Гаилә әгъзалары турында табышмаклар</u>**


Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул, барыбыздан олы ул. (Әби)

Ул бик күпне күргән, сугышта да булган ул.
Йөзе нурлы айдай… Кем дисезме? Ул минем (бабай).

Ул зирәк тә, шаян да, акыллы да, әйбәт тә!
Иң – иң батыр кеше ул, минем (әти), әлбәттә!

Мин аны бик сагындым, күңелем әрни, уйлый әллә ни.
Кем соң аны белми? Ул бит минем (әни).

***Бергәләп өйрәник***



***8 март – әни бәйрәме***
***Әти-әниләр өчен ярдәмлек***
***(5-6 яшь)***

**Атна темасы: "8 март - әни бәйрәме"**

Зурлар төркеме өчен

**Мәкальләр:**

Өйнең яме ана белән.
Әни суккан авыртмый.
Өйнең яме ана белән.
Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.
Ана – шәфкать диңгезе.
Әни суккан авыртмый.
Ата – беләк, ана – йөрәк.
Балага иң куәтле кеше – ата.
Ата-ананы тыңламаган, олыгайгач үзе дә игелек күрмәс.
Ата-ана теләге утка-суга батырмас.
Ана – шәфкать диңгезе. (*Эчтәлеге буенча фикер алышу)*

**Җыр тыңлау**: «Әни кирәк» (Р.Миңнуллин сүзләре, М.Шәмсетдинова көе).

Фикер алышу.

- Көннәр якты булсын өчен кем кирәк? - Йокы татлы булсын өчен кем кирәк?
- Җил-яңгырдан саклар өчен, усаллардан яклар өчен кем кирәк?
- Ашлар тәмле булсын өчен, дөнья ямьле булсын өчен кем кирәк?
- Гөлләр чәчәк атсын өчен, бәхет-шатлык артсын өчен кем кирәк?

Иң кадерле кеше җирдә кем, димәк?

**Дидактик уен** «Кемнең әнисе кайда эшли?» (магнитлы так та ярдәмендә). Балалар рәсемнәр буенча һөнәр ияләрен билгелиләр. Мәсәлән: тегү машинасы рәсеме – тегүче; ризыклар, савыт-саба рәсемнәре – пешекче һ.б.

**Санамыш**. [ч] авазы.

Әлчи-бәлчи,
Әни миңа күлмәк үлчи.
Үлчи торгач, җитмәде,
Кисә торгач, бетмәде.
Чәүкә, чыпчык,
Син кал, бу чык.

**Әниләр турында хикәя төзү.**

Максат: бәйләнешле сөйләм телен үстерү, әниләргә хөрмәт тәрбияләү.

Әйдәгез әниләр турында сөйлик: —Минем әниемнең исеме ...(*Гөлназ).* Ул уртача буйлы. Аның күзләре ...(*зәңгәр*), чәчләре кыска көрән һ.б. Нинди кием кияргә ярата? Әниләргә нинди матур сүзләр әйтер идегез?

**Әни гөлләре.** Автор: Н. Гайсин

Әни утыртты гөлләр,
Алар үсә зур булып,
Утыралар ямь биреп,
Бөтен өебез тулып.
Мин аларга су сибәм
Яки иртән, я кичен.

Әниемә булышам
Эше азайсын өчен.
Хуш исле нәфис гөлләр
Үсәләр биек булып,
Утыралар ямь биреп,
Бөтен өебез тулып!